# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылында 2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**18.11.2022 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Минзәләбаш авылында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәкләр), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнар, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, № 647 указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (керү төркемен төзү (төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эш өчен түләү), су җыю урынын төзекләндерү (төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), чишмә юлын ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эш өчен түләү), эскәмия сатып алу).

3. Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
МБ башлыгы Р.Ә. Каримов